Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 март 2020 ел № 369

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 19 маендагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының мактаулы гражданины турында»гы 72 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына таянып, хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 19 маендагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының мактаулы гражданины турында»гы 72 нче номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 19 октябрендәге 234 нче номерлы, 2015 елның 23 октябрендәге 18 нче номерлы, 2015 елның 29 декабрендәге 45 нче номерлы, 2016 елның 10 августындагы 85 нче номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 204 нче номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 306 нчы номерлы, 2019 елның 16 декабрендәге 347 нче номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтада «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының мактаулы гражданины» исемен бирү документларын карау буенча комиссия составы»:

1.1.1. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Мөхәммәдиев Рөстәм Нәбиулла улы - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАЖ генераль директорының социаль үсеш буенча урынбасары (килешү буенча)»;

1.1.2. 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Токарев Александр Михайлович - Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины, Әлмәт шәһәре башлыгының даими нигездә урынбасары»;

1.2. 3 нче кушымта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины турында нигезләмә» 3 бүлек 3.10 пунктта «Мактаулы исемгә лаек булган затларга куелган ташламалар һәм игътибар билгеләре»:

1.2.1. өченче абзацта «күмүне оештыру» сүзләрен «күмүне оештыруга чыгымнарны каплау» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.2. дүртенче абзацта «әзерләү һәм урнаштыру» сүзләрен «әзерләү һәм урнаштыру чыгымнарын каплау» сүзләренә алмаштырырга.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU)

һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Салахов И.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов